ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.11.2020 № 895

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 августындагы 541 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 4.08.2020 ел, №541 карары белән расланган җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 статьяның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт (алга таба - махсуслаштырылган хезмәт) - Нурлат районы Башкарма комитеты тарафыннан төзелгән оешма, аңа үлгәннәрне җирләү гарантияләрен үтәү буенча вәкаләтләр йөкләнә һәм түләүсез нигездә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеген күрсәтү бурычы йөкләнә. Махсуслаштырылган хезмәт үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, Нурлат муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, әлеге Тәртипкә таяна.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Хәмзин